РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

16.04.2018 | № 77-п

Саба муниципаль районы
инвалидлар Советы составына
үзгәрешләр кертү турында

Саба муниципаль районы инвалидлар Советының кайбер затларының вазыйфаларыннан китүләре һәм яңа вазыйфага билгеләнүләре сәбәпле

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районы Башлыгының “Саба муниципаль районы инвалидлар Советы төзү турында”гы 25.05.2012 ел 37-п номерлы карары белән (01.12.2016 ел 184-п номерлы, 23.01.2017 ел 9-п номерлы; 23.10.2017 ел 189-п номерлы карарлары редакцияләрендә) расланган Саба муниципаль районы инвалидлар Советы (алга таба - Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Совет составыннан М.Р. Ишниязовны, Т.Г. Шәрәфиевне чыгарырга;

1.2. Совет составына Баһманов Марат Мансур улын - Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарын - икътисад бүлеге начальнигын кертергә;

1.3. Санарга:

- М.М. Хуҗинны - Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Саба муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигын - Совет рәисе урынбасары итеп (килешү буенча);

- М.В. Галиуллинны - Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан төбәк бүлеге (БҖИ ТТБ) Саба җирле оешмасы рәисен - Совет сәркатибе итеп (килешү буенча).

Р.Н. Минниханов